**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**

**Әлкәй авыл җирлеге Советы карары**

Әлкәй авылы № 111 08.10. 2018 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Советының 04.05.2018 №95 «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлегенең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» карары белән расланган Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең, муниципаль хезмәткәрләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 17 октябрендәге 940 номерлы карары нигезендә

Әлкәй авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Советының 04.05.2018 №95 «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлегенең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» карары белән расланган Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең

хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәреш кертергә:

2.2 пунктының икенче абзацында «4,65» санын «6,72» санына алмаштырырга.

(2.2 пунктының икенче абзацында «5,55» санын «7,71» саннарына алмаштырырга - Тымытык авыл җирлеге өчен - 11 хезмәт өчен түләү төркеме)

2. Әлеге карар 2018 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны веб-адрес буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда игълан итәргә: http://pravo. tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча урнаштырырга: http//aznakayevo. tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис: С.З.Зиннурова